| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **с.Старое Дрожжаное** | **КАРАР** |

2020 елның 28 сентябре №1/5

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (2018 елның 11 маендагы 27/3 номерлы карары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 1 пунктта** «11 163,0 сум» сүзләрен «11 498,00 сум» сүзләренә алмаштырырга;

**2) «МУНИЦИПАЛЬ ВАЗЫЙФАЛАРНЫ ДАИМИ НИГЕЗДӘ БИЛӘГӘН ЗАТЛАРГА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОННЫҢ КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ ҺӘМ ШАРТЛАРЫ» 1 нче кушымтасындагы**

таблицаны

“

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район Башлыгы | 29 555 | | | |
| Муниципаль район Башлыгы урынбасары | 26 600 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 26 600 | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | | 13 561 | | |
| Авыл җирлеге башлыгы | | | 16 750 | 15 300 |

”;

түбәндәге редакциядә бирергә:

“

| Вазыйфа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 30 442 | | | |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 27 398 | | | |
| Контроль-хисап органы рәисе | 27 398 | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы урынбасары | | 13 968 | | |
| Авыл җирлеге башлыгы | | | 17 253 | 15 759 |

”;

**3) 2 нче кушымтаны** түбәндәге редакциядә бирергә:

“2 нче кушымта
Расланды
Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Советының 2018
елның 30 мартындагы
26/1 номерлы карары
белән (Татарстан
Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы
Советының
2010 елның 28
сентябрендәге 1/5
номерлы карары
редакциясендә)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| Вазыйфа атамасы | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Район Башкарма комитеты җитәкчесе | 29 895 |
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 27 135 |
| Район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары | 26 906 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе | 26 790 |
| Эшләр идарәчесе - Район Башкарма комитетының оештыру бүлеге начальнигы | 25 180 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 24 606 |
| Бүлек начальнигы | 20 927 |
| Район Башлыгы киңәшчесе | 18 283 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 18 283 |
| Район Башкарма комитеты җитәкчесенең ярдәмчесе | 18 283 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 18 283 |
| Бүлек мөдире | 16 902 |
| Баш белгеч | 16 212 |
| Әйдәп баручы белгеч | 15 063 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 11 498 |

”,

**4) 3 нче кушымтаны** түбәндәге редакциядә бирергә:

“3 нче кушымта
Расланды
Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Советының 2018
елның 30 мартындагы
26/1 номерлы карары
белән (Татарстан
Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы
Советының
2010 елның 28
сентябрендәге 1/5
номерлы карары
редакциясендә)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ОКЛАДЛАРЫ КҮЛӘМЕ**

| | Вазыйфаларның атамалары | Вазыйфаи оклад | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| 1. | Башкарма комитет җитәкчесе | 18 742 | | |
| 2. | Башкарма комитет сәркәтибе | | 16 902 | 15 292 |
| 3. | Әйдәп баручы белгеч | 12 763 | | |
| 4. | 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 11 498 | | |

”.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров